**Хәнәфи МАННАПОВ,**
*«Коммунизм байрагы» газетасының баш мөхәррире*

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

Яр Чаллы шәһәре республика буйсынуындагы шәһәргә әверелгәч, 1963 елның 1 апреленнән башлап, КПСС шәһәр комитетының район һәм шәһәр Советлары башкарма комитетлары органы булып, Чаллы районында элек чыгып килгән «Знамя коммунизма» – «Коммунизм байрагы» газетасы кабат чыгарыла башлады. Татар телендә чыга торганы русчадан җәрҗемә газета булуга да карамастан, аның редакциясенә беренче көннәрдә үк шигырьләр, парчалар һәм очерк, хикәяләр күп килә башлады. Мөстәкыйль булмаган, атнасына дүрт тапкыр чыга торган газета редакциясенең штаты бик кечкенә булуы сәбәпле (редакторның тәрҗемә буенча урынбасары, ул ук секретарь һәм ике тәрҗемәче) әдәби эшне алып баруны штаттагыларның кайсына булса да боерык белән тапшыру мөмкин түгел иде. Чөнки дубляж газета пресс-бюро, АПН мәкаләләрен дә, прессклише подтекстларын да татар теленә урында тәрҗемә итәргә туры килә. Бу зур эшкә, ягъни көн саен газета чыгаруга, бик киеренке эшләгәндә дә, эш сәгатьләре җитәр-җитмәс булып кала, ә күп вакыт эш сәгатьләреннән тыш та калып эшләргә туры килә. Әмма авылларда мәктәпнең әдәби түгәрәкләре членнарыннан һәм башка авторлардан кульъязмалар туктаусыз килеп тора һәм һәр автор үзенең кульъязмасы турында редакциянең фикерен беләсе килүе турында да яза, киңәш сорый. Шул ук 1963 елның 1 сентябренә редакциягә килгән әдәби кульъязмалар шактый күп җыелган һәм шактый калын папка булган иде инде. Авторларның өметләрен ничектер акларга, сорауларына җаваплар һәм киңәшләр бирергә кирәк иде.

1963 елның октябрендә Татарстан Язучылар союзы идарәсе, «Коммунизм байрагы» редакциясенең үтенечен канәгатьләндереп безгә шагыйрь Зәки Нури иптәшне җибәрде. Ул кульъязмаларның барысын да укып чыкты, өметлерәк авторларның исемлеген төзеп, аларны редакциягә чакырырга тәкъдим итте. Өч көннән соң безнең редакциягә шигырь, парчалар һәм хикәяләр язучы җиде автор җыелды. Беренче карлыгачлар иделәр болар. Зәки Нури аларның һәрберсе белән аерым-аерым да сөйләште, шигырь өстендә ничек эшләргә кирәклеге, әдәбият теориясен өйрәнү турында кыйммәтле киңәшләр бирде. Яхшы дип табылган кульъязмаларны «Коммунизм байрагы» газетасында бастырып чыгарырга тәкъдим итте.

Бу беренче зур эш иде, әлбәттә. Әмма бу авторлар җыелышының зуррак әһәмияте дә булды. Ул «Коммунизм байрагы» редакциясе каршында әдәби түгәрәкне оештыру ягыннан формалаштырды. Нәтиҗәдә газетада беренче әдәби сәхифә дә басылып чыкты. Яшь авторларга әдәбият дөньясына чыгу юлында зур ярдәм иде бу. Эшче һәм колхозчы яшьләр, татар мәктәпләрендә укучылар редакциягә үзләренең кульъязмаларын, хәтта шигырьләр, парчалар, альбомнарын да алып килә башладылар.

Зәки Нуриның безгә икенче килүендә инде әдәби түгәрәккә 12 автор җыелганда кызыклырак, эшлеклерәк формада үтте. Түгәрәкне оешу ягыннан

ныгыта һәм камилләштерә төште. Членнары төрле түгәрәкләрдән җыелганга күрә, редакция каршындагы әдәби оешма шул түгәрәкләр белән җитәкчелек итү функциясен дә үз өстенә алды һәм аңа «Әдәби берләшмә» исеме бирелде. Монысы 1964 елның январенда булды һәм шул вакыттан башлап «Коммунизм байрагы» газетасы ай саен бер әдәби сәхифә чыгара башлады. Моннан тыш та атна саен әдәби почмаклар бирелә, ә көн бурычын чагылдырган шигырьләр, хикәяләр, әдәби сәхифәне яки почмакны көтеп тормастан, газета битенә оператив тәртиптә урнаштырыла барды.

Татарстан Язучылар союзы правлениесенең якыннан ярдәм күрсәтүенә таянып, без әдәби берләшмә семинарын ике ай саен бер тапкыр үткәрә килдек. Семинар көннәре итеп газета чыгарылмый торган көннәр билгеләнде, ә атнага ике ял көнле бишкөнлек эш атнасына күчкәч – шимбә көннәрне үткәрә торган булдык. Яшь шагыйрьләребезгә аеруча актив ярдәм күрсәтүчеләрдән, Зәки Нуридан кала, шагыйрь Мәхмүт Хөсәенне дә күрсәтәсе килә. Ул безнең әдәби берләшмә семинарларында еш булды, авторларыбыз белән аерым-аерым сөйләште. Ә әдәби берләшмәнең бер семинарын без яшь шагыйрәбез Сәлимә Шәрипова эшләгән һәм яшәгән колхозга барып, аның авыл интеллигенциясе, хезмәттәшләре һәм колхоз җитәкчеләре катнашында үткәрдек. Шул семинар алдыннан «Коммунизм байрагы» газетасының өченче бите Сәлимә Шәрипова иҗатына багышлап чыгарылды. Ә семинардан соң аны Казан телестудиясенә чакырып алдылар, һәм ул телевидение буенча үзенең шигырьләрен укыды.

Бу эшне оештыруда шагыйрьләр М. Хөсәен һәм М. Садри иптәшләр якыннан торып булышлык күрсәттеләр.

Безнең әдәби берләшмә, яшь көчләр хисабына үсә барып, 1964 ел ахырына 22 кешегә җитте. Ул елны безнең «Коммунизм байрагы» газетасында әдәби почмаклардан тыш 13 әдәби сәхифә басылып чыкты. Өметлерәк күренгән яшьләрдән М. Әгъләмов, Разил Вәлиев, Х. Хөснуллин, Р. Хисамиев һәм башкалар әдәби берләшмә эшендә аеруча актив катнаштылар. Әдәби сәхифәләрдә шушы иптәшләрнең шигырьләре, хикәяләре, парчалары һәм мәсәлләре дөнья күрә килде. Бу елны, образлы итеп әйткәндә, әдәби берләшмәнең чәчәккә бөреләнү чоры дип күрсәтергә була.

Тагын бер елдан әдәби берләшмәгә яңа каләм көчләре өстәлде. Шундыйлардан Анатолий Цыганов, Сәмига Сәүбәнова, Габделхәй Метшин, Гамир Гайфетдинов, Рифкать Муллин, Фәннур Сафин, Хәбирә Шаһиева һәм башка иптәшләрне күрсәтергә мөмкин.

1965-1966 еллар әдәби берләшмәнең чәчәк ату чоры булды. Туплана килгән көчләрне кирәгенчә, юнәлешле тәрбияләү өчен, без әдәби берләшмәнең эшен, билгеле бер программа буенча, планлы рәвештә алып барырга тырыштык. Яшьләрне туплауга, үстерүгә, әдәби хезмәтләрен дөньяга чыгаруга һәм үзләрен дә халык массасы алдына чыгаруга бөтен көчебезне, мөмкин кадәр вакытыбызны биреп эшләдек. Берләшмәдә катнашучы яшь каләм көчләре арасыннан бер генә шагыйрь, язучы яки драматург үсә алса да, әдәби берләшмә үзенең максатына ирешкән, димәк, көчебез бушка китмәгән дип саный идек.

Бу ел дәвамында «Коммунизм байрагы» газетасында 18 әдәби сәхифәдә 14 әдәби почмакта яшь авторларыбызның 127 шигыре һәм 29 хикәя нәсерләре басылып чыкты. Ә 1966 елда исә бу саннар тагын да үсә төште: әдәби сәхифә һәм почмакларда 32 хикәя һәм 133 шигырь басылып чыкты. Һәвәскәр композиторларыбыз Хәмит Булатов һәм Зөфәр Сәгыйтов кайбер яшь авторларыбызның сүзләренә музыка яздылар. Ә район Культура йортының үзешчән сәнгать коллективы ул җырларны үзләренең сәхнә программаларына да кертте. Яшь авторлар М. Әгъләмов, Г. Метшин, С. Шәрипова, Х. Хөснуллин һәм башка иптәшләр үзләренең шигырьләрен Культура йортында, клубларда халык алдында һәм җирле радио буенча да укый башладылар.

Бу вакытта әдәби берләшмә оешкан көч булып өлгерде, аның штаттан тыш җитәкчесе булып авторларның берсе – Х. Хөснуллин эшләде, җитәкче бюро да сайланды. Берләшмә семинарларында Х. Хөснуллин, М. Әгъләмов, Разил Вәлиев иптәшләр әдәбият теориясеннән кайбер мәсьәләләр буенча лекцияләр белән чыгыш ясый килделәр.

Без әдәби берләшмә эшен активлаштыру, Эчтәлеклерәк итү максатыннан кызыксындыру чаралары да кулландык. Аерым алганда, Х. Хөснуллин Уфага иҗади командировка белән бүләкләнде. Ә М. Әгъләмов Казанга командировка бирелде.

Бу уңышларга ирешү безнең үз көчләребез белән генә мөмкин булмас иде, әлбәттә, Язучылар союзы правлениесе вәкиле әдәби берләшмә семинарларының һәрберсенә дип әйтерлек катнаша килде. Шагыйрьләр З. Нури һәм М. Хөсәеннән тыш, безнең башлап язучыларыбызга Р. Ишморат, Н. Дәүли һәм башка иптәшләр дә урынга килеп булыштылар. Якташыбыз язучы Сөббух Рафиков та яшь авторларга якыннан торып зур ярдәм күрсәтте, семинарларда әдәби күзәтүләр белән чыгышлар ясады. Болардан тыш безнең күп кенә авторларыбызны Татарстан Язучылар союзы правлениесенә аерым консультацияләргә чакырып та зур ярдәм күрсәттеләр. Биредә семинар башланганчы кульязмаларны укып, өйрәнеп авторларга файдалы киңәшләр бирделәр. Моннан тыш, авторларның шигырьләренә, парчаларына, мәсәлләренә анализ ясалган мәкаләләр «Коммунизи байрагы» газетасы битләрендә бастырылды. Шундыйлардан Р. Гәрәйнең «Яшьлеккә ташлама юк» исемле зур мәкаләсен, М. Хөсәеннең С. Шәрипова иҗатына багышланган зур мәкаләсен һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Болардан тыш, бу иптәшләр, әдәби берләшмә членнарының безнең газетада басылып чыккан шигырьләре, басылган кульязмалары арасыннан иң яхшыларын сайлап алып, «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталарына әдәби битләргә тәкъдим иткәләделәр. Яшьләр газетасында, мәсәлән, безнең авторларыбызның шигырьләреннән шундый берничә сәхифә һәм «Канат чыгарганда» исемле зур мәкалә басылып чыкты. Авторларыбызның кайбер шигырьләре «Чаян», «Ялкын», «Азат хатын» һәм «Казан утлары» журналларында да басылып чыкты.

Болар безнең яшь авторларыбызны әдәби тормыш эзенә бастыруда, олы юлга таба юнәлеш бирүдә зур этәргеч булдылар. Авторларны үстерүдә аларга белем бирү аеруча кирәкле. Шуны искә алып, без өметлерәк булган

авторларыбызга Казан дәүләт университетының филология факультетында укырга тәкъдим иттек.

Соңгы еллар «Коммунизм байрагы» каршында эшләүче әдәби берләшмә членнарыннан берничәсенең иҗат эшләрендә олы юлга таба адымнары белән билгеләнде. Х. Хөснуллин, М. Әгъләмов, С. Шәрипова, Равил Вәлиев һәм башка кайбер иптәшләрнең шигырьләре, парчалары Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан әдәби җыентыкта урын алдылар. Бераз соңрак китап нәшрияты Разил Вәлиевның кечерәк кенә булса да үз шигырьләре җыентыгын чыгарды.

«Социалистик Татарстан» газетасы узган елның ахырында безнең актив һәм әдәбиятка кыю атлаучы яшь авторыбыз М. Әгъләмовның берничә шигырен аерым бүлек итеп басып чыгарды. Шунысы куанычлы, бу бүлектә республикабызның олы шагыйре С. Хәкимнең яшь авторга изге теләкләр белән җылы язылган мәкаләсе дә чыкты. С. Хәким үзенең бу мәкаләсендә Мөдәрриснең кыю, өметле шагыйрь булуын таныган, аның хәтта кайбер якларын Маяковскийга охшатканлыгын әйткән һәм яшь авторга хәерле юл теләвен белдергән иде.

М. Әгъләмов олы шагыйрьнең бу фикерләрен аклый да. Ул узган кышта Татарстан районнарында һәм колхозларында укучылар массасы алдында үзенең шигырьләре белән кыю чыгышлар ясап йөрде, Башкортостан башкаласы Уфада да булып кайтты. Ә хәзер бу яшь авторның шигырьләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятында аерым китап итеп басылып чыгуга хәзерләнә. Барлас Камал да «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкаләсендә аның бу шигырьләре турында уңай фикерләр әйткән. Татарстан радиосы буенча да Мөдәррис Ә. шигырьләре яңгырады һәм алар турында матур фикерләр әйтелде.

Болар безне бик куандыра, әлбәттә. Әмма тагын бер авторыбызның уңышы турында телгә алмасак, әдәби берләшмә эше турында бик мөһим нәрсә әйтелми калыр иде. Бу – драматургия жанрындагы беренче уңышлы адым. Бу жанрда эшләүче безнең әдәби берләшмә члены Зәйнәп ханым Җиһаншина яшь кеше түгел. Ул – газетада озак еллар эшләгән журналист һәм Чаллы халык театрының актив һәм танылган артисткаларыннан берсе. Аның очерклары, хикәяләре өлкә газеталарында да басылып чыкты. Ә 1967 елда ул биш пәрдәлек драма әсәре язды. Авылда колхоз төзелешенең беренче елларында сыйнфый көрәш кискенлеген чагылдырган һәм беренче күмәк хуҗалыкның җиңүен онытылмас образларда күрсәткән, кискен конфликтларга нигезләнгән бу әсәр «Төнге шәүләләр» дип исемләнгән һәм ул Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1967 елда басылып чыккан «Күңелле сәхнә» исемле зур җыентыкка кертелгән.

Шунысы куанычлы, Зәйнәп Җиһаншинаның «Төнге шәүләләр»ен Чаллы халык театры үз репертуарына алды һәм спектаклен Татарстан районнарының культура йортлары, колхоз һәм совхоз клублары сәхнәләрендә күрсәтте. Театр Октябрь революциясенең 50 еллыгына багышланган «Төнге шәүләләр» спектаклен Казан тамашачыларына да күрсәтеп, зур уңыш казанып кайтты. Спектакль өчен театрга II Дәрәҗә диплом бирелде.

Болар барысы да әдәби берләшмә члennары арасыннан иҗат эшендә олы юлга таба атлаучылар турында. Ә безнең район күләмендә эшләүче һәм «Коммунизм байрагы» битләрендә басылып килүче авторларыбыз да бар. Болары – колхозларда, предприятиеләрдә һәм төзелеш оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр. Аларның кайберләрендә шигырь, мәсәл һәм парчалар язу сәләте көчле. Алар производство алдынгылары образларын шигырьләрендә, хикәяләрендә чагылдырдылар, иҗтимагый тормышта булган һәр вакыйга турында үз фикерләрен әйтәләр.

Гомуми уңышлар өчен шигырь сөюче укучылар белән бергә куанып, һәр җиңү, бәйрәм яки тормышта булган әһәмиятле вакыйга өчен шатлык хисләре, көр күңел белән матур образлы шигырьләр, мәсәлләр тудыралар алар.

*// Якты юл. – 1983. – 6 нояб.*